# НИК СОҢЛАДЫҢ?

*(Романс)*

*Илсөяр Ганиева сүзләре*




14
rit.
сай - рый, дус-ка тиң-ләп ял - гыз ти - рәк - не.
rit.
sf
19
A tempo
p
Ни-гә соң-лап кил-дең, а-сыл ко-шым ми-нем, дул-кын-ла -
A tempo
p
24
1.2.
3.
тып моң - су йө - рәк - не? // рем.




Таң атканда, бер сандугач сайрый,
Дуска тиңләп ялгыз тирәкне.
Нигә соңлап килдең, асыл кошым минем,
Дулкынлатып моңсу йөрәкне?

Аерылган аккошлар шикелле,
Мин дә синең кебек моңаям.
Гомерем буйларына яндырырга мине
Соңлап кына килдең син каян?

Яшьлегемнең алсу таңнарында
Юк идең бит, нигә килмәдең?
Аерылсак та, җуймас йөрәккәем сине,
Зарыгып кына көткән тиңнәрен.